ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 3 14 март 2024 ел

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә, татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 9 ноябрендәге 28 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 октябрендәге 20 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4 пунктының 4.4 пунктчасына ярашлы,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 25 мартында 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында, 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

2.1. «2023 елның 22 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 5 санлы карарын гамәлдән чыгарырга сез ризамы?».

2.2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Ак-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә ризамы һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

- Ак Чишмә торак пунктында һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга мемориаль такта кую (проектын төзү, проектны төзү буенча хезмәтләр күрсәтү, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, нигез салу, мемориал кую, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев